КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 21 март г.Казань № 300

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты мәсьәләләре» 2018 ел, 12 июль, 565 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты мәсьәләләре турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты мәсьәләләре» 2018 ел, 12 июль, 565 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 13 март, 179 нчы; 2019 ел, 18 сентябрь, 846 нчы; 2020 ел, 28 февраль, 153 нче; 2020 ел, 25 август, 734 нче; 2020 ел, 22 декабрь, 1172 нче; 2021 ел, 26 июль, 649 нчы; 2021 ел, 7 декабрь, 1182 нче; 2022 ел, 28 февраль, 180 нчы; 2022 ел, 13 май, 439 нчы, 2022 ел, 19 сентябрь, 1016 нчы, 2022 ел, 24 октябрь, 1134 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.3 пунктта «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең» сүзләренә алмаштырырга;

1.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.7. Комитетның урнашкан урыны (адресы): 420015, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Карл Маркс ур., 56/11.»;

3.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле 3.3.27[1] пунктча өстәргә:

«3.3.27[1]. Әлеге Нигезләмәнең 3.3 пунктындагы 3.3.27 пунктчада күрсәтелгән объектларны дәүләт кадастр исәбенә алу турында гаризаны теркәү органына җибәрә;»;

5.1 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры                                                                 А.В.Песошин